| | |
|---|---|
| РУКОВОДИТЕЛЬ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО<br>КОМИТЕТА КУРАЛОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>КУРАЛОВО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ<br>ҖИТӘКЧЕСЕ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |

09.11.2022 с. Куралово 03-10/27

Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2022 елның 25 октябрендәге 1 номерлы һәм 2022 елның 29 октябрендәге 2 номерлы Куралово авыл җирлегенең торак пунктларында гражданнар җыенында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында Куралово авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Куралово авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе Т. Ю. Тимиряева

Югары Ослан
муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 9 ноябреннән
03-10/27 номерлы
карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегендә
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү гражданнар җыенында катнашуга бәйсез рәвештә Югары Ослан муниципаль районының Куралово авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар һәм алар тарафыннан тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә 01.01.2023 елдан алып 31.03.2022 елга кадәр гамәлгә ашырыла.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) 1 төркем инвалидлар

б) мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары

4. Түләүләр күләме гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:

а) күпбалалы гаиләләр,

б) уку йортлары студентлары,

в) тыл хезмәтчәннәре

5. Бер мәртәбә бирелә торган түләүне түләү турында хәбәрнамә (хәбәр итү) бланкы почта элемтәсе аша юллама бирү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар түләүләрен физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмалары) яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча күчерү хокукы булган оешмалар аша күчерү юлы белән башкарыла

8. Түләү фактын раслау булын приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслый торган башка документлар тора.

9. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Югары Ослан
муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 9 ноябреннән
03-10/27 номерлы
карарына
2 кушымта

ХӘБӘРНАМӘ (ХӘБӘР) № _______________
Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүченең Ф. И.О.
___________________________________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________
____________________________________________________________ нигезендә
Сезгә ________________________ вакытына кадәр
_____________________________________________________ чараларны тормышка
ашыру өчен ______________ сум күләмендә,
түбәндәге реквизитлар буенча:
____________________________________________________ бер тапкыр акча түләргә
кирәк.
Алучының банк БИК _______________________________________
Сч. № ___________________________________
Алучының сч. №__ . __________________________________________
ИНН ___________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК ________________ ОКАТО___________________
Түләүне билгеләү
_______________________________________________________________________

Җитәкче __________________ _________________________________________
М. п. (имза) (имзаны киңәйтеп язу)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәрнамә (Хәбәр) № _________________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында _______________________
(муниципаль берәмлек исеме)
_________________ сум күләмендә.
Түләүченең Ф. И.О _________________________________________________________
Адрес:
___________________________________________________________________________
Алдым "__" __________________ 20___ ел. _______________________________
(түләүченең имзасы)
*Искәрмә. Аермалы корешок тутырыла һәм хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырылса,* _______________ *авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*